# ТАТАР-КЫРГЫЗ ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫ

***Исламов Р.Ф.****, филология фәннәре докторы,*
***Габдулхакова Г.М.***

# TATAR-KYRGYZ LITERARY AND CULTURAL INTERRELATIONS

***Islamov R.F, Gabdulkhakova G.M.***

Татар-кыргыз багланышларының ерак гасырларга сузылган тарихы бар. Бу барыннан да элек Урта Азиянең, шул ук вакытта, кыргызларның да, Россия империясе тарафыннан яуланып алынуы һәм үз составына кертүе белән бәйле. Шул сәбәпле татар сәүдәгәрләре, тылмачлар, дин әһелләре, интеллигенция вәкилләре күпләп шул тарафларга, ягъни яңа җирләргә күченә башлый. Боларга шулай ук көчләп чукындырудан, рекрутлыктан, ачлык афәтләреннән, җирсезлектән җәфа чиккән крестьяннар да кушыла.

Бу һиҗрәт, дулкын-дулкын булып, репрессия елларында да, Бөек Ватан сугышыннан соң да, зур төзелешләр уңае белән дә дәвам итә.

Билгеләнгән теманың аерым аспектлары фәнни нигездә берникадәр өйрәнелде. Әйтик, тарихчы Миркасыйм Госманов (1934–2010) үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Дөрес, татар-кыргыз әдәби һәм культура мөнәсәбәтләре тарихы әле җентекләп өйрәнелмәгән; шуңа күрә безнең халыклар арасындагы багланышларның кайсы чорларда ничек башланып китүен тәгаен әйтүе хәзергә читенрәк. Шулай да XIX йөзнең урталарында, кыргыз халкының тарихын, әдәби мирасын өйрәнүне башлап җибәрүгә, рус һәм башка милләт вәкилләре белән бергә, татар галимнәре дә катнаша. Мәсәлән, «Манас» эпосының кыскача вариантын тарихта беренче булып 1856 елны атаклы казах галиме Чукан Вәлиханов язып алган булса, аны беренче булып укып тикшергән, беренче булып эпосның гыйльми әһәмиятен билгеләгән, аның милли хосусиятләрен тотып алган галимнәрнең берсе күренекле татар мәгърифәтчесе, көнчыгыш телләре белгече Хөсәен Фәезханов иде»[1].

Дөрестән дә, Х. Фәезхановның (1828–1866) 1863 елның 8 апрелендә казакъ мәгърифәтчесе, тарихчы, этнограф һәм фольклорчы Чокан Вәлихановка (1835–1865) язган хатында шундый юллар бар: «Ул Сезнең дәфтәрләрегез арасында[гы] «Күкәтай хан иртәгәсе» казакъ иртәгәсен[нән] бераз башкарак күренәдер. Аны Сез кайдан алдыңыз, ул Сезнең җортларда бик мәшһүрме? Шуның хикәйтен йазсаңыз икән дип үтенәмен. [Ул]

йахшы нәрсәдәй күренәдер»[2]. Билгеле булганча, «Күкәтай хан иртәгәсе» «Манас» эпосының бер өлешен тәшкил итә һәм «Бу текстны Ч. Вәлиханов 1856 елны Эссе Күл буйларында язып алган һәм аны соңрак Х. Фәезхановка биреп торган. Димәк, хаттан күренгәнчә, истәлеккә беренче фәнни бәя бирүче, аның гыйльми әһәмиятен дөрес билгеләүче Х. Фәезханов була»[3].

«Манас» эпосы турында сүз алып барганда, без тагын бер милләттәшебезне тирән ихтирам белән искә алырга тиешбез. Ул – кыргыз мәгарифен үстерүгә, фольклор мирасын җыйнап-туплау эшендә зур хезмәт куйган, әмма гомере фаҗигале өзелгән зыялыларның берсе Каюм Гайнан улы Мифтахов (1892–1948). Уфа губернасы Златоуст өязе (хәзер Башкортстан Республикасының Салават районы) Нәсибаш авылында туган, казакъ, уйгыр, үзбәк, кыргыз, төрекмән, каракалпак телләрен камил белгән бу шәхес манасчы Сагымбай Орозбековтан (1868–1930) «Манас» эпосының тулы вариантын язып ала[4].

Милләттәшебез – тюрколог, фольклорчы, әдәбият галиме Мәдинә Богданованың (1908–1962) да «Манас» эпосын өйрәнүгә зур өлеш керткәнлеген тәкъдир итү урынлы булыр.

Бу уңайдан шуны да әйтергә кирәк, «Манас»ның аерым бүлекләре типография ысулы белән Казанда 1896, 1899 елларда китап булып басылып чыга. «Манас» әсәрен татар җирлегендә өйрәнү алга таба да бәрәкәтле дәвам иттерелә. Мәсәлән, тарихчы М. Госманов аңа берничә тәфсилле мәкалә багышлый[5], аның фәнни җитәкчелегендә Билал Чыныбаев (1963–2008) кандидатлык диссертациясе яклый[6]. Әдәбият галиме Ф. Галимуллинның бу ядкяргә багышланган мәкаләсе зур кызыксыну уята[7].

Ош дәүләт педагогия институты укытучысы Сатыбалды Мамытов (1957–2006) Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында филология фәннәре докторы, профессор Н.Г. Юзиев (1931–1996) фәнни җитәкчелегендә «XIX йөз уртасы – XX йөз башларында кыргыз-татар әдәби бәйләнешләре» дигән темага диссертация язып яклый[8]. Аннары ул хезмәтен аерым монография итеп бастыра[9].

Кыргыз-Россия Славян университетының өлкән укытучысы Әминә Галимова XIX йөз ахыры – XX йөзнең беренче яртысында кыргыз һәм татар шигърияте багланышларын, Г. Тукай лирикасы поэтикасын кыргыз шагыйрьләре Молдо Кылыч, Мукай Элебаев (1905–1943) һ.б. иҗатлары мисалында тикшерә[10].

Кыргызстандагы татарлар турында Й. Баласагуни исемендәге Кыргызстан милли университеты профессоры, тарих фәннәре докторы Әнисә Бикбулатова махсус монография әзерләп бастыра[11]. Анда татар диаспорасының барлыкка килү тарихы, үсеш динамикасы, республиканың төрле өлкәләрендә урнашуы, белем үзләштерү дәрәҗәсе һәм социаль-профессиональ шөгеле мәсьәләләре яктыртыла. Хәзерге вакытта эшләп килүче «Туган тел» татар-башкорт иҗтимагый

оешмасының эшчәнлегенә анализ ясала.

Татар сәүдәгәре Габделкадыйр Милүшев кыргыз җирләренә 1879 елда килеп урнаша һәм, җиләк-җимеш белән сату итеп, 1883 елда Токмак шәһәрендә бай кешеләрнең берсенә әверелә[12]. Алга таба аның эшен Мөхәммәтсадыйк исемле улы дәвам иттерә.

Каракол шәһәрендә сәүдә-сәнәгать оешмалары Хәмзә Габделвәлиев (әнисе ягыннан Чыңгыз Айтматовның (1928–2008) бабасы) карамагында була. А.Г. Кәримов тегермән тота, галантерия товарлары белән бертуган Дәүләтшиннар, бакалея әйберләре белән бертуган Идрисовлар, мануфактура белән В.Г. Рәфыйков, Х. Габделвәлиев һ.б. сәүдә итә[13].

Шәһәрләрдәге кайбер урамнар татар сәүдәгәрләре исемнәре белән аталган. Мәсәлән, Пишпәктә (хәзерге Бишкәк) Татар урамыннан тыш Исхак (Исхак Дәвелбаев) урамы да булган (хәзерге Мәскәү урамы)[14].

Татар сәүдәгәрләренең династияләре билгеле. Мәсәлән, Муллаҗановлар, Моратовлар һ.б. Аларның нәселләре Бишкәк шәһәрендә әле дә яши.

1850–1855 елларда Каракол шәһәрендә мәчет төзелә. Ул яшь имам Мөхтәрулла Бәширов җитәкчелегендә башкарыла. 1878 елда икенче мәчет нигезләнә. Ул корылып тәмамлангач, аңа имам итеп Шакир Мөҗәбиров билгеләнә[15].

Татар-кыргыз багланышлары алгарышында төрле хәйрия җәмгыятьләре дә зур роль уйнаган. Мәгълүм булганча, «Пржевальск шәһәрендәге «Татар-кыргыз җәмгыяте хәйриясе»нең үз китапханәсе, үз залы була. Ыссык-Күл буеның унбер волостеннан кыргызлар, татар мөгаллимнәре, сәүдәгәрләр аның әгъзасы була»[16]. Җәмгыять китаплар бастыру белән дә шөгыльләнә.

Кыргызстан җирләрендә мәгариф тарату, мәктәп-мәдрәсәләр ачу эше иң беренче чиратта татар укымышлыларының исемнәре белән бәйле, әлбәттә. Мәсәлән, Самара губернасы Богырыслан өязе Котлымбәт авылыннан шагыйрь, педагог Сабир (Габдессабир) Фәхретдин улы Габделмәновның (1879–1917) гомере 1902 елдан башлап Кыргызстандагы Токмак шәһәрендә уза[17]. Ул анда «Мәдрәсәи икъбалия»да мөгаллим була. Аның «Фөрьядлар»[18], «Нәтиҗәи әхлак. Хикмәтле сүзләр вә хикәяләр»[19] исемле китаплары дөнья күрә. Беренче җыентыгы милли колониаль изүгә каршы кискен каршылыкка корылган эчтәлекле булу сәбәпле конфискацияләнә, автор үзе берничә ай төрмәдә утырып чыга.

С. Габделмәновның аерым шигырьләре Токмак шәһәренең татар байларыннан берсе булган Мөхәммәтсадыйк Милүшевның Казанда 1908 елда басылган «Кардәшләремә ядкяр» дип аталган китабында да урын алган[20]. Аның язмалары «Шура» журналында, «Кояш» газетасында даими басыла. Алар арасында табигать, җирле тормыш турындагылары да бар[21].

Уфа губернасы Бәләбәй өязе Җилдәр волостеның (хәзерге Башкортстан Республикасы Миякә рай-

оны) Баязит авылында туып-үскән язучы, педагог Гали Рәфикый (Гали Лотфрахман улы Рәфыйков, 1890–1944), Уфадагы «Галия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, берничә ел Пишпәк шәһәрендәге алты сыйныфлы «Иҗтиһад» мәдрәсәсендә балалар укыта, аларга табигать белеменнән һәм географиядән сабак бирә[22]. Анда яшәгән вакытта ул шактый сәяхәт итә, кыргыз халкының тормыш-көнкүреше белән якыннан таныша, аларның гореф-гадәтләрен өйрәнә, табигатьләре белән кызыксына. Шушы истәлекләргә таянып язган «Ыссык күл», «Алатау буйларында», «Вакытлы никах», «Зилзилә» һәм башка әсәрләрен Казанда нәшер ителүче «Аң» журналында, Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасында бастыра.

1914 елда Фазылбәк Касыймов тарафыннан Ош шәһәрендә җәдит мәктәбе ачылуы мәгълүм.

Заманында татар мәктәпләрендә кыргыз балаларының да тәгълим-белем алганлыклары халык язучысы Кубанычбәк Маликовның (1911–1978) татар теленә тәрҗемә ителгән «Үзем татар булмасам да…» шигыренең түбәндәге ике строфасында ачык әйтелгән:

*Татарның мәктәбен күрдем мин,*
*Ишеген ачып кердем мин, –*
*Габдулла, Галимҗан булдылар*
*Һәрвакыт мендәрем урнында!*

*Мин татар түгелмен – кыргызмын.*
*Татардан сабаклар укыдым,*
*Остазлар каршында баш иеп,*
*Шәкертлек дәверен уздым мин*[23].

Кыргыз яшьләренең Идел һәм Урал буе уку йортларында белем алулары мәгълүм. Атаклы «Галия» мәдрәсәсе шәкертләре арасында, мәсәлән, язучы, тарихчы Османлы Садыйков (1875–1942)[24], Мамбеталы Надыркул, Токтоналы Чынгышев, Исхак Канатов, Ишеналы Арабаев, К. Шабданов[25] һ.б. бар.

Күренекле кыргыз мәгърифәтчесе И. Арабаев (1882–1933) 1910 елда Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә укырга керә һәм бер елдан соң «Галия»гә күчә. Анда Хафис Сасекеев исемле казакъ шәкерте белән, «Әлифба йаки төтө окуу» («Әлифба, яки тиз укуга өйрәтү») төзеп, 1911 елда Уфадагы «Шәрык» матбагасында бастырып чыгаралар[26]. Бу кыргыз телендә беренче басма китап була. Шәхсән үзе язган «Жазуу өрнөктөрү» («Язу үрнәкләре») китабын 1912 елда Оренбургта нәшер итә.

Шулай ук Казан университетында белем алулары да мәгълүм. Әйтик, хокук факультеты студенты Кожомурат Сарыкулаков (1892–1918), 1916 елда якташларының патша колонизаторларына каршы күтәрелешен ишеткәч, «Кара туман» («Кара караңгылык») исемле мәкалә язып, кульъязмада тарата[27].

Мәгариф турында сүз алып барганда, без совет хакимияте чорын да билгеләп үтәргә тиешбез. Мәсәлән, чыгышы белән Башкортстаннан булган Бөек Ватан сугышы ветераны, математик Әкрам Вәли улы Вәлиев (1913–2009)[28], Татарстаннан физика-математика фәннәре кандидаты Мостафин Сабирҗан улы Җәүдәт (1919–2008), филология фәннәре кандидаты, доцент Николай Миф-

тах улы Морадымов Ош дәүләт педагогия институтында (хәзерге А. Мырсабеков исемендәге Ош дәүләт педагогия университеты) укытты. Бу уңайдан шунысын да әйтергә кирәк, Н.М. Морадымов, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында филология фәннәре докторы, профессор Н.Г. Юзиев фәнни җитәкчелегендә аспирантура узып, «Әхмәт Фәйзи поэзиясендә герой һәм чор проблемасы» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый[29]. Моны, икенче яктан, тугандаш республика өчен филология юнәлешендә кадрлар әзерләү мәсьәләсе яссылыгында да карарга мөмкин.

Шунысы кызык, шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй (1888–1937) Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк кыргызлар тормышы хакында язылган бер китапны татар теленә тәрҗемә итеп бастыра[30].

Мәгълүм Октябрь түнтәрелешенә кадәр һәм аннан соң да кыргыз язучыларының әсәрләре татар матбагаларында нәшер ителә. Мәсәлән, шагыйрь Кожоназар (Хуҗаназар) Ошиның (18 йөз) «Рәхәти дил» («Күңел тынычлыгы») әсәре, Молдо Кылычның (1866–1917) «Кыйссаи зилзилә» поэмасы 1911 елда Казанда аерым китап булып дөнья күрә. О. Сыдыковның «Кыргыз таварихы» (1907), «Мохтасар тарихы кыргызия» (1913), «Тарихы кыргыз Шадмания» (1914) китаплары Казанда, Оренбургта, Уфада басыла.

Язучы, драматург, репрессия чоры корбаны Сыдык Карачевның (1900–1937) «Торымтай» хикәясе 1917 елда Уфада аерым китап булып нәшер ителә[31].

Татар-кыргыз әдәби багланышлары мәсьәләсенә килгәндә, барыннан да элек халык шагыйре Габдулла Тукай (1886–1913) исеме калкып чыга, чөнки, тугандаш башка төрки халыкларның әдипләре кебек үк, кыргыз язучылары да аның иҗаты белән гарәп хәрефләрендә нәшер ителгән басмаларыннан ук таныш булалар. Мәсәлән, Кыргызстанның халык шагыйре, Кыргыз ССРы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Социалистик Хезмәт Герое Аалы Токомбаев (1904–1988) бу хакта болай яза: «Үземнең беренче шигырьләремне чын мәгънәсендә халык шагыйре, интернациональ шагыйрь Габдулла Тукайның көчле эмоциональ тәэсирендә яздым»[32]. Язучы һәм тәрҗемәче Камчы Җунусов (1915–1988) 1936 елда Ош шәһәрендә авыл хуҗалыгы техникумында укыган вакытында Мәхмүт Гафаров исемле татар сабакташы ярдәмендә Тукай әсәрләрен өйрәнүе турында яза[33].

Совет хакимияте чорында кыргыз әдәбияты белән киң гавам укучыларны таныштыра башлау Бөек Ватан сугышы алды елларына туры килә. Мәсәлән, «Совет әдәбияты» журналының 1940 елгы 9–10 нчы кушма санында шагыйрь Токтогул Сатылгановның (1865–1933) Октябрь түнтәрелешенә кадәрге һәм аннан соңгы тормышын яктырткан мәкалә бастырыла[34].

1954 елда Татарстан язучыларының III съезды була. Анда катнашкан кыргыз язучысы Касыма-

лы Баялинов (1902–1979) үзенең чыгышында, татар язучылары әсәрләренең кыргыз теленә тәрҗемә ителүе хакында сөйләп, Габдулла Тукай, Гомәр Бәширов, Кави Нәҗми исемнәренә аеруча басым ясый. Шул ук вакытта Татарстанда кыргыз язучыларының әсәрләре билгесез булуга гаҗәпләнеп, болай ди: «Мин, бирегә килгәч, кыргыз язучыларының нинди әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән икән дип кызыксындым. Аерым шигырьләрне алмаганда, бер генә кыргызча китап та татар телендә чыкмаган. Минемчә, татар китап издательствосы үзенең эшендәге бу кимчелекне искә алыр»[35].

Әйе, күрсәтелгән кимчелек алга таба төзәтелү юнәлешен ала. Кыргыз язучыларының әсәрләре татар көндәлек матбугатында әледән-әле басыла башлый. Әйтик, «Казан утлары» журналының 1965 елгы 4 нче санында «Кыргыз поэзиясеннән» рубрикасында Токтогул Сатылгановның «Эшкә өйрән», Кубанычбәк Маликовның «Памир юлы», Темиркул Үмөталиевның (1908–1991) «Виноград» дип аталган шигырьләре басыла[36]. «Социалистик Татарстан» газетасының 1972 елгы 26 апрель санында кыргыз шагыйрәсе Майрамкан Абылкасымованың (1936–2021) «Безнең байрак» исемле шигыре[37], 13 сентябрь санынды К. Маликовның «Үзем татар булмасам да…», Т. Адышеванын «Шигърият», «Мәхәббәтем» шигырьләре, 10, 12, 13 сентябрь саннарында һәм «Казан утлары» журналының 12 нче санында[38] Чыңгыз Айтматовның (1928–2008) «Әйләнеп кошлар кайтканчы…» исемле әсәре дөнья күрә.

Бу эш хәзерге вакытта да дәвам иттерелә. Мәсәлән, «Татарстан» журналының 1994 елгы 3–4 нче кушма санында Алыкул Осмоновның (1915–1950) «…Котырса да көчле кар-бураннары…» шигыре Сәйдә Зыя тәрҗемәсендә[39], «Мәйдан» журналының 2018 елгы 3 нче һәм 7 нче саннарында Айдарбәк Сарманбетовның «Мөртәт», «Изге үр» хикәяләре Р. Бәшәр һәм Л. Шәех тәрҗемәләрендә дөнья күрә[40].

1962 елда Н. Арсланов тәрҗемәсендә «Кыргыз халык әкиятләре» аерым китап булып басылып чыга[41]. 1970 елда З. Нури егерме ике кыргыз шагыйренең әсәрләрен туплап бастыра[42]. 1972 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан «Кыргыз хикәяләре» җыентыгы дөнья күрә[43]. Анда уналты язучының әсәре тупланган. Җыентык хакында сүз йөртеп, язучы Фатих Хөсни: «Мин монда ул хикәяләргә анализ ясауны максат итеп куймадым. Ләкин шатлык хисе белән бер нәрсәне билгеләп үтәсем килә: иптәшләр тормыш фактларына уйланып, җанлы кеше, аның үзенчәлекле язмышы, психологиясе аша якын киләләр. Яссылык, озынлык үлчәве белән генә түгел, тирәнлек, эчке каршылыклар, тетрәткеч вакыйгалар аша киләләр»[44], – дип яза.

Җыентыкка мөнәсәбәтле бәяләмәсендә язучы, филология фәннәре кандидаты М. Мәһдиев (1930–1995) болай ди: «Берәүгә дә сер түгел, бу китап чыкканчы күбебезнең кыргыз әдәбияты турында иң зур мәгълүматы – Чыңгыз Айтматов

һәм аның әсәрләре буенча гына иде. Карасаң – Чыңгыз Айтматов бүгенге кыргыз прозасында һич тә ялгыз түгел икән»[45]. Аннары ул Мар Байҗиевның (1935–2021) «Елмаю», Чыңгыз Айтматовның «Солдат улы», Камбарлы Бобуловның (1936–2003) «Иркенбәк», Ашым Жакыпбековның (1935–1994) «Айкашка», Роза Рыскелдинованың (1934–2021) «Кызыл кашлы йөзек», Мурза Гапаровның (1936–2002) «Кара күлнең казлары» исемле хикәяләренә кыскача анализ ясый, аларга карата үзенең фикерләрен белдерә.

Кыргыз әдипләреннән Токтогул Сатылганов[46], Камчы Җунусов[47], К. Баялинов[48], Ч. Айтматов[49] китаплары нәшер ителде.

2015 елда Татарстан китап нәшриятында «Төрки әдәбиятлар» сериясе булдырыла. Шул нигездә кыргыз язучылары Омар Солтанов[50], Айдарбәк Сарманбетовның[51] әсәрләре татар телендә аерым китап булып басыла.

Татар көндәлек матбугатында кыргыз әдипләренең иҗатлары турында язмалар басылу хакында да әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, Ч. Айтматовка 50 яшь тулу уңае белән М. Госманов «Казан утлары» журналында аның иҗат эшчәнлеген әтрафлы яктырткан аналитик мәкалә бастыра[52]. Галим, игътибарын әдипнең аеруча «Җәмилә», «Ак пароход», «Диңгез яры буйлап йөгерүче Ала эт» әсәрләренә юнәлтеп, аларда күтәрелгән проблемаларга һәм аларның чишелешенә, әдәби чараларның кулланылыш үзенчәлекләренә, кыргыз халык иҗаты материаллары белән иҗади эш итү моментларына тукталып уза.

Галимнең икенче мәкаләсе Ч. Айтматов белән очрашуларын (1961, 1972, 1986) яктыртуга, аның шәхесен һәм иҗат эшчәнлеген тагын да тулырак ачуга багышлана. Аерым алганда, язмасын ул шул рәвешле тәмамлый: «Чыңгыз Айтматовның гомум иҗатына, бу гаҗәеп якты, чын ихлас иҗатның тулаем әһәмиятенә, гомумкешелек дәрәҗәсендәге кыйммәтенә, шулай ук язучының тормыш юлына, тәрҗемәи хәлендәге кайбер үзенчәлекләргә килсәк, югарыда китерелгән мәгълүматларга, әйтелгән фикерләргә таянып, мин үзем өчен – әйе, үзем өчен – түбәндәге нәтиҗәләрне чыгардым: бөек язучы Чыңгыз Төрәкол угылы Айтматов үзен катгый рәвештә кыргыз кешесе һәм кыргыз әдибе итеп тойган, инанган, шул иманда торып иҗат иткән, ахыргача шулай калган бербөтен – бүленмәс шәхес; әгәр аның олы иҗатын хөрмәт итүебез ихлас булса, аның кемлек хакындагы ихтыярын да берсүзсез таныргa, кабул кылырга тиешбез; шулай гына ул барыбыз өчен дә уртак була ала»[53].

Әдипнең тормышы, иҗат эшчәнлеге, аның белән шәхсән очрашу мизгелләре хакында филология фәннәре докторы, профессор Х. Миңнегуловның шушы елларда гына басылып чыккан бер мәкаләсе зур кызыксыну уята[54].

Ике республика арасында әдәбият көннәре уздыру шулай ук үзара багланышларның күркәм бер чагылышы булып тора. 1972 елның сентябрь аенда РСФСРда кыргыз әдәбияты көннәре Татарстанда башланып китә. Бу танта-

нага Кыргызстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре Тендик Әскәров (1937–2019), халык язучылары, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматов, Кубанычбәк Маликов, Темиркул Үмөталиев, шагыйрьләр Суюнбай Эралиев (1921–2016), Субайылда Абдыкадырова (1935–2010), республика комсомол премиясе лауреаты Турар Кожомбердиев (1941–1989), Тенти Адышева (1920–1984), прозаиклар Насирдин Байтемиров (1916–1996), Шукурбек Бейшеналиев (1928–2000), Асанбек Стамов (1938–2010), «Литературный Кыргызстан» журналының баш мөхәррире Александр Жирков килә.

Тантананы ачу кичәсе 11 сентябрь көнне М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында була. Анда Т. Әскәров, чыгыш ясап, болай ди: «Татар әдәбияты белән кыргыз әдәбияты арасында элемтәләр дә тирәнәйде. Безнең укучыларыбыз Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Ф. Сәйфи-Казанлы, Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, Г. Бәширов, Г. Кутуй, С. Хәким, З. Нури һәм башкаларның әсәрләрен яхшы беләләр һәм яраталар. Алар күп тапкыр кыргыз теленә тәрҗемә ителделәр»[55].

Ч. Айтматов үзенең чыгышында шулай дип белдерә: «Минемчә, бүген шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Урта Азиянең хәзерге милли культуралары формалашуында чын-чынлап революцион йогынты ясаган рус культурасы һәм әдәбияты белән бергә кыргыз әдәбиятына, аерым алганда, татар халык әдәбияты, татар художество һәм мәгърифәтчелек фикере зур йогынты ясады»[56].

Концерт өлешендә Кыргызстан ССРның халык артисты Асек Жумабаев (1924–2005), атказанган артистлары Хөсәен Мухтаров (1938–2001), Токтонолы Сейталиев (1937–2021) чыгыш ясый.

Кыргыз әдәбияты көннәре кысаларында республика китапханәсендә татар һәм кыргыз язучылары катнашында хикәя жанры турында зур әңгәмә үткәрелә. Аерым алганда, Чыңгыз Айтматов хикәяне заман мозаикасы дип атый, аның җәмгыять, кешелек дөньясы турында гомуми күзаллау тудырырга тиешлеге турында сөйли. Хикәядән башка зур прозаның була алмавын, һәр язучы хикәя иҗат итү этабын үтәргә тиешлеген әйтә һәм бу жанрга игътибарны арттырырга чакыра.

«Литературный Киргизстан» журналы редакторы Александр Жирков, филология фәннәре кандидатлары Мөхәммәт Мәһдиев, Флүн Мусин, Кыргызстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре, философия фәннәре кандидаты Тендик Әскәров, тарих фәннәре кандидаты Миркасыйм Госманов үзләренең чыгышларын хикәя жанрының төрле проблемаларына, тәрҗемә һәм әдәби әсәрләрне пропагандалау мәсьәләсенә багышлыйлар[57].

2000 елда Ч. Айтматов, Казакъстанның халык язучысы Олжас Сөләйманов белән махсус Казанга килеп, Татарстан язучылары белән очраша. 2006 елда каһарман шагыйрь М. Җәлилнең тууына 100 ел тулуга багышланган чараларда катнашып, М. Җәлил исемендәге Татар опера

һәм балет театрында үткәрелгән кичәдә чыгыш ясый. Үзенең 80 яшьлек юбилее уңае белән тормыш юлы һәм эшчәнлегенә багышланган «Гасырдан да озынрак көн» исемле кинофильмның бер өлешен төшерү максатында 2008 елның май аенда тагын Казанга килә, чөнки Кукмара районында әнисенең ата-бабалары чыккан авылга бару планлаштырылган була. Ни аяныч, әдип кинәт кенә авырып, аның бу нияте гамәлгә ашмый кала.

Совет хакимияте вакытында Кыргызстанда татар әдәбияты белән танышуның торышы ничегрәк була соң?

Бу хакта Кыргызстанның халык язучысы, СССР дәүләт пермиясе лауреаты, академик Тугельбай Сыдыкбеков (1912–1997) болай дип яза: «Без, ягъни төрки әдәбиятлар язучылары, татар әдәбиятының нигезе булган халык иҗаты үрнәкләре, бай фольклоры белән әдип һәм галим Нәкый Исәнбәтнең өч томлык хезмәте аша яхшы таныш. Габдулла Тукайдан башлап, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким кебек татар шагыйрьләрен, Галимҗан Ибраһимовтан башлап Кави Нәҗми, Гомәр Бәширов, Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов кебек язучыларның әсәрләрен, романнарын, повестьларын кыргыз укучылары яхшы белә. Аерата «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Язгы җилләр», «Намус» романнары, «Тапшырылмаган хатлар» повесте безнең укучыларның сөйгән әсәрләренә әверелделәр.

Татар совет әдәбиятының үсешен, анда булган һәр яңалыкны кыргыз язучылары даими күзәтеп баралар. Моны бездән тормыш үзе таләп итә. Шулай булганда гына милли әдәбиятлар үзара иҗади элемтәдә торалар һәм бу элемтәләр әдәбиятлар үсешенә нәтиҗәле йогынты ясый ала»[58].

Г. Тукайның әсәрләре кыргыз телендә 1948 елда дөнья күрә[59]. Икенче басмасын К. Җунусов белән язучы, шагыйрь, кыргыз әдәбиятында беренче профессиональ тәрҗемәчеләрнең берсе Узакбай Абдукаимов (1909–1963) әзерләп бастыра[60]. Бу хакта К. Жунусов үзе шулай аңлата: «Тукайның кыргыз телендәге сайланма җыентыгының беренче басмасында аның төп әсәрләре барысы да урнаштырылмаган иде. Шуңа күрә, кыргыз телендә Тукай әсәрләренең тулырак яңа басмасын чыгарырга кирәк дип табылды һәм аны төзү эше миңа тапшырылды»[61]. Г. Тукайның төрле юбилейлары уңае белән кыргыз көндәлек матбугында мәкаләләр дә дөнья күрде[62].

Шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең (1906–1944) аерым шигырьләре («Җырларым», «Хат», «Иркәм», «Ишек төбендә», «Бер кызга», «Юллар», «Кыз җыры»), беренче мәртәбә 1953 елда ук Кубанычбек Маликов тарафыннан кыргыз теленә тәрҗемә ителеп, «Советтик Кыргызстан» журналында бастырылды[63].

М. Җәлил шигырьләре кыргыз телендә өч басмада, ягъни 1957[64], 1962[65], 1979[66] елларда нәшер ителде. Беренче басмасы уңае белән язган бәяләмәсендә тәнкыйтьче Салижан Жигитов тәрҗемәдәге

(тәрҗемәчеләр – Камчы Жунусов, Төлөн Шәмшиев (1913–2001) шактый кимчелекләрне күрсәтте һәм аның яңадан эшләнергә тиешлеген белдерде[67].

Шагыйрь әсәрләренең Түмөнбай Байзаков (1923–1992) тәрҗемәсендәге икенче басмасы турында сүз йөртеп, әдәбият белгече Керимкул Абдылдабеков болай дип яза: «Т. Байзаков хезмәтенең аерым кыйммәте янә шунда ки, ул үзенең тәрҗемә итү эшчәнлегендә әсәрләрнең мәгънәсен, сәнгати бөтенлеген генә түгел, ә шагыйрьнең индивидуль стилен, шигырьләрендәге сәнгати чараларын һәм ысулларын, лириклыгын һәм музыкальлеген дә сакларга тырышкан»[68]. Галимнең бу мәкаләсендә М. Җәлилнең янә башка әсәрләренең дә кыргыз теленә тәрҗемәләре турында кызыклы мәгълүмат табарга мөмкин.

Нәби Дәүлинең (1910–1989) «Көр оозунда» («Яшәү белән үлем арасында») повесте (1969), Җәвад Тәрҗемановның (1920–1995) «Шуктуган» әкият-повесте (1987) шулай ук аерым китап булып басылып чыкты.

1972 елда Кыргызстан китап нәшриятында татар язучылары Әхмәт Исхак (1905–1991), Нури Арслан (1912–1991), Гамил Афзал (1921–2003), Әмирхан Еники (1909–2000), Мирсәй Әмир (1906–1980), Шәүкәт Галиев (1928–2011), Зыя Мансур (1916–1965), Фатих Хөсни (1908–1996), Сафа Сабиров (1915–2004), Роберт Батулла һәм башкаларның юмористик һәм сатирик әсәрләре тупланган «Ашкабак» җыентыгы нәшер ителә[69].

Кыргыз көндәлек матбугатында шулай ук татар шагыйрьләре һәм язучылары Мәхмүт Хөсәеннең (1923–1993), Самат Шакирның (1924–1998), Гариф Ахуновның (1925–2000), Роза Хафизованың (1928–2005), Кояш Тимбикованың (1937–2004), Рәфкать Кәраминең аерым әсәрләре дөнья күрә.

Соңгы елларда яшь язучы Ленар Шәехнең «Амбал малай» исемле әсәре кыргыз һәм рус телләрендә басылып чыкты[70]. «Кара жорго, Акбозат» дип аталган җыентыкта казакъ, төрек, әзәрбайҗан, гагауз, кабарда, балкар әдипләре белән бергә Ләбиб Лерон, Ленар Шәехнең әсәрләре дә урын алган[71].

Гариф Ахунов (1925–2000) 1997 елда Ч. Айтматовны 50 яше белән котларга Кыргызстанга бара. Язучының тууына 85 ел тулу уңаеннан Кыргызстан Республикасы делегациясе Татарстанда була. Аның составында Кыргызстанның мәдәният, мәгълүмат һәм туризм министры Солтан Раев, Кыргызстан Республикасының Россия Федерациясендәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Болот Джунусов һ.б. була. Язучының 90 еллык юбилеена багышлап, 2018 елның 12 декабрендә Казанда «XX гасырның икенче яртысында милли әдәбиятлар яңарышы һәм Чыңгыз Айтматов» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрелде. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов һәм Дәүләт Советы рәисе урынбасары Р.А. Ратникова Бишкәк шәһәрендә уздырылган язучылар һәм интеллектулларның «Айтматов укулары цивилизацияара

диалог өчен» дигән Халыкара форум эшендә катнашты (2017). 2019 елда Татарстан Фәннәр академиясендә «Глобаль үзгәрешләр чорында кеше һәм мәдәният» дигән темага Чыңгыз Айтматов укулары уздырылды.

2000 елның яз аенда Кыргызстан Республикасы Хөкүмәтенең беренче вице-премьеры Б. Силаев җитәкчелегендәге делегация Татарстанда була.

Ике республика югары даирә җитәкчелегенең үзара аралашуы үзенең уңышлы нәтиҗәләре белән әһәмиятле. 2006 елның февралендә Татарстан Республикасы Президенты М.Ш. Шәймиев Кыргызстанның Россия Федерациясендәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле вәкиле Апас Җомагуловны, язучы Ч. Айтматовны, 2008 елда Раимкул Аттакуровны кабул итә. Бу очрашулардагы әңгәмәләрдә сүз ике республика арасындагы сәүдә-икътисад һәм мәдәният мәсьәләләре хакында алып барыла.

2017 елның җәендә Татарстанда Кыргызстан мәдәнияте көннәре булып уза. Тантанага Кыргызстан Республикасы Президенты Алмазбәк Атамбаев хатыны Рәисә Минәхмәт кызы белән килә. Мәдәният көннәрендә Әсәнхан Җумәхмәтов исемендәге Дәүләт симфоник оркестры, Кыргызстанның филармония һәм опера артистлары чыгыш ясый, А. Малдыбаев исемендәге Кыргыз опера һәм балет академия театрының генераль директоры Болот Осмонов, Кыргызстан Кинематографистлары берлеге рәисе, кинорежиссёр, продюсер Садыйк Шер-Нияз һәм Татарстанда Кыргызстан мәдәнияте көннәре координаторы Дарика Асылбашева катнашында «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында матбугат очрашуы да үтә, Казанның «Мир» кинотеатрында кыргыз фильмнары күрсәтелә[72].

Татарлар Кыргызстанның сәхнә сәнгатен үстерүгә дә зур өлеш кертә. Әйтик, Пермь шәһәрендә туып үскән Р.Х. Уразгилдиев (1935–2015) сәнгать фәннәре докторы, профессор, Кыргызстан Республикасының халык артисты дәрәҗәсенә иреште. Үзенең бер хезмәтендә опера һәм балет өлкәсендә хезмәт куйган татар чыгышлы Маһинур Мостаева (1912–1997), Мөнҗия Еркимбаева (1918–1976), Булат Минжилкиев (1940–1997), Айсылу Токомбаева, Клара Надыршина, Эрик Латыйпов һ.б.ның исемнәрен китерә.

Узган гасырның 70 нче елларында Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры труппасының Кыргызстанда булып узган уңышлы гастроль чыгышлары ике республика арасында мәдәни элемтәләр ныгуның ачык дәлиле булып тора. Фрунзе тамашачылары бу талантлы коллектив башкаручыларының зур осталыгы белән таныша. Театр Ч. Айтматов әсәре буенча эшләнгән «Гүзәлем Әсәл» спектаклен күрсәтә[73].

Халыкара төрки халыклар театрлары фестивале кысаларында 2019 елда Бишкәк шәһәренең Б. Кыдыкеева исемендәге Кыргызстан дәүләт яшь тамашачылар театры Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Тунҗәр Җуҗәноглуның «Ташкын» трагедиясе буенча,

быел М. Рыскулов исемендәге Нарын өлкә академия музыкаль-драма театры Ч. Айтматовның «Беренче мөгаллим» әсәре буенча спектакльләр куя.

Татарстанның Чистай шәһәрендә туып үскән, Кыргызстан Рәссамнар берлеге әгъзасы Ринат Хәнәфиев хәзерге вакытта Бишкәк шәһәрендә яши һәм иҗат итә. Ул туган якларын онытмый, 2021 елда Чистайда оештырылган ике пленэрда катнаша[74].

Шулай итеп, без кыргыз-татар бәйләнышлары мәсьәләсен аның куелышы тәртибендә генә карап үттек. Киләчәктә аларның һәрбер юнәлеше, әлбәттә биредә күрсәтелмәгәннәре дә, тәфсилле өйрәнелер һәм яңадан-яңа тикшеренүләр барлыкка килер дип ышанабыз.

**Сведения об авторах:** Исламов Рамил Фанавиевич, доктор филологических наук, главный научный сотрудник Центра энциклопедистики Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: usman.58@mail.ru; Габдулхакова Гульшат Мансуровна, научный сотрудник Центра изучения татарской диаспоры Института татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: sofa-hakova69@mail.ru.

**Аннотация.** В статье освещаются некоторые аспекты татаро-киргизских литературно-культурных связей, в частности, просветительская деятельность татарских учителей и преподавателей среди киргизского народа; пропаганда достижений в области литературы и культуры обоих народов в периодической печати, издание произведений киргизских писателей и поэтов на татарском языке, татарских – на киргизском языке; проведение дней литератур и культур в обеих республиках; обмен опытом сценического искусства.

**Ключевые слова:** Татаро-киргизские литературно-культурные связи, татарская литература, киргизская литература, просвещение, поэты, писатели, татарская диаспора.

**Abstract.** The article highlights some aspects of Tatar-Kyrgyz literary and cultural ties, in particular, the educational activities of Tatar teachers and teachers among the Kyrgyz people; the promotion of achievements in literature and culture sphere of both peoples in the periodical press, the publication of works of Kyrgyz writers and poets in the Tatar language, Tatar – in the Kyrgyz language; the days of literature and culture in both republics; the exchange of experience in performing arts.

**Key words:** Tatar-Kyrgyz literary and cultural ties, Tatar literature, Kyrgyz literature, enlightenment, poets, writers, Tatar diaspora.

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Госманов М. Яшәргән халыкның ялкынлы әдәбияты // Социалистик Татарстан. – 1972. – 13 сент.

2 Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / Фәнни мөх. М. Госманов, төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – Б. 440–441.

3 Шунда ук. – Б. 446.

4 Мифтахов Н. Ул да бит шушы татарның бер газиз баласы ла… // Мәдәни җомга. – 1996. – 28 июнь; Токомбаева А. Каюм Мифтахов – кыргыз фольклорунун жыйнаоочусу жана изилдөөчүсү // Ала-Тоо. – 1988. – № 1. – Б. 125–129.

5 Усманов М.А. Изучение эпоса «Манас» и уроки манасоведения // Вклад татарских ученых в изучение «Манаса»: тез. докл. и сообщ. – Бишкек: Кыргызский сельскохозяйственный ин-т, 1994. – С. 5–6; Усманов М.А. Богатырская поэма (к 1000-летию эпоса «Манас») // Научный Татарстан. – 1995. – № 5. – С. 81–84; Усманов М.А. Начало изучения эпоса «Манас» и значение манасоведения для тюркской филологии (Уроки «Манаса») // Манас. – Бишкек: Кыргызский сельскохозяйственный ин-т, 1995. – С. 8–15;

Усманов М.А. «Манас» һәм татарлар // Татарстан хәбәрләре. – 1995. – 3 февр.

6 Чыныбаев Б.С. Историко-этнографический аспект изучения эпоса «Манас» (историография проблемы): автореф. дис … канд. ист. наук; КГУ. – Казань, 1991. – 19 с.

7 Галимуллин Ф. «Манас» – халык ядкяре // Безнең мирас. – 2022. – № 4. – Б. 66–67.

8 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков: автореф. дис … канд. филол. наук; ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КНЦ РАН. – Казань, 1992. – 20 с.

9 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков. – Бишкек: Мурас, 1999. – 177 с.

10 Галимова А.Р. Литературные связи киргизской и татарской поэзии конца XIX – первой половины XX в. – Бишкек: Кыргызско-российский славянский ун-т им. Б.Н. Ельцина, 2015. – 142 с.

11 Бикбулатова А.Р. Татары Кыргызстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – С. 35.

12 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков. – Бишкек: Мурас, 1999. – С. 49–50.

13 Бикбулатова А.Р. Татары Кыргызстана. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2020. – С. 69.

14 Там же. – С. 73.

15 Лотфуллин Г.З. История строительства татарской мечети в Караколе // Татары и башкиры в Кыргызстане: материалы науч.-практ. конф., посвящ. 1000-летию Казани и 200-летию Казан. гос. ун-та / Под ред. С.Ф. Усманова. – Бишкек: Изд-во КРСУ, 2005. – С. 89–90.

16 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков. – Бишкек: Мурас, 1999. – С. 77.

17 Әхмәтҗанов М. Сабир Габделмәнов (1879–1917) // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. – Казан, 2005. – Б. 61–62.

18 Фөрьядлар. Мөхәррире: Сабир бине Фәхретдин Габделмәнов. Наширләре: Пржевальның Татар вә кыргыз җәмгыяте. – Казань: Электро-тип. Шараф, [елы юк]. – 54 б.

19 Нәтиҗәи әхлак. Хикмәтле сүзләр вә хикәяләр. Мөхәррире: Йидесу вилаяте Тукмак касәбәсенең Габделсабир бине Фәхретдин Габделмәнев. Нашире: Йидесу вилаяте Пишпәк бәлдәсенең 2 нче дәрәҗә купецы мөхтәрәм Мөхәммәтсадыйк бине Габделкадыйр Милүшев. Харитонов матбагасы. – Казань: Лито-тип. И.Н. Харитонова. – 1909. – 9 б.

20 Кардәшләремә ядкяр. Тукмак, Пишәк өязе Семиречински обласының Мөхәммәтсадыйк Габделкадыйр угылы Милүшевның хәраҗәте илән табыг улынды. Казанда «Шәрык» матбагасы. – Казань: Электро-тип. Шараф, 1908. – 50 б.

21 Габделмәнов С. Тянь-Шань тавының тирән чокырларыннан // Шура. – 1913. – № 2. – Б. 60–63; № 3. – Б. 126–128; № 5. – Б. 158–160; Габделмәнов С. Тянь-Шань тавында бер кечек сәяхәт // Кояш. – 1914. – 23 авг.

22 Рафиков М. Мәгърифәтче. Язучы. Педагог // Кызыл таң. – 1990. – 11 июль.

23 Маликов К. Үзем татар булмасам да… // Социалистик Татарстан. – 1972. – 13 сент.

24 Рәхимов С. «Галия» мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 127.

25 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков. – Бишкек: Мурас, 1999. – С. 71.

26 Әлифба йаки төтө окуу. Мөрәттиб вә наширләре: Мәдрәсә Галийәдәге кыргыз вә казакъ шәкертләре. – Уфа: «Шәрык» матбагасы, 1911. – 52 б.

27 Семенков В. Сын народа // Советская Киргизия. – 1969. – 22 нояб.

28 Сафронова М. Жизнь, прожитая с верой в человека. – Ош, 2005. – 27 с.

29 Мурадымов Н.М. Проблема героя и эпохи в поэзии Ахмеда Файзи: автореф. дис. … канд. филол. наук; ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова КФ АН СССР. – Казань, 1979. – 14 с.

30 Тунгатаи: кыргызлар тормышыннан // Мөтәрҗиме С. Сүнчәләй. Нашире: Сабах көтепханәсе. – Казан: Лит.-тип. И.Н. Харитонова, [елы күрсәтелмәгән]. – 31 б.

31 Мамытов С.А. Кыргызско-татарские литературные связи второй половины XIX – начала XX веков. – Бишкек: Мурас, 1999. – С. 78.

32 Акчурин В. Гомер бакый дөнья гизүчеләр // Идел. – 1998. – № 10. – Б. 32.
33 Җунусов К. Тукай яши // Совет әдәбияты. – 1961. – № 4. – Б. 44.
34 Кыргыз халкының бөек ерчысы Токтогыл Сатылганов // Совет әдәбияты. – 1940. – № 9–10. – Б. 136–137.
35 Баялинов К. Бергәләп, яңа уңышларга! // Совет әдәбияты. – 1954. – № 8. – Б. 116.
36 Кыргыз поэзиясыннан // Казан утлары. – 1965. – № 4. – Б. 107–108.
37 Абылкасыймова М. Безнең байрак // Социалистик Татарстан. – 1972. – 26 апр.
38 Айтматов Ч. Әйләнеп кошлар кайтканчы… // Казан утлары. – 1978. – № 12. – Б. 96–112.
39 Османов А. Котырса да көчле кар-бураннар… // Татарстан. – 1994. – № 3–4. – Б. 16.
40 Сарманбетов А. Мөртәт // Мәйдан. – 2018. – № 3. – Б. 108–114; Сарманбетов А. Изге үр // Мәйдан. – 2018. – № 7. – Б. 46–59.
41 Кыргыз халык әкиятләре / Кыргызчадан Н. Арсланов тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 123 б.
42 Кыргыз шагыйрьләре / Төз. һәм тәрҗ. З. Нури. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. – 55 б.
43 Кыргыз хикәяләре / Төз. Х. Хөсәенова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. – 291 б.
44 Хөсни Ф. Хикәя турында уйлану (Кыргыз һәм татар язучыларының әдәби очрашулары уңае белән) // Социалистик Татарстан. – 1972. – 13 сент.
45 Мәһдиев М. Кайда «Ак пароход»ыбыз? // Казан утлары. – 1973. – № 4. – Б. 170–171.
46 Сатылганов Т. Сайланма әсәрләр / Төз. һәм тәрҗ. Н. Арсланов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 100 б.
47 Җунусов К. Син биргән чәчәк: Шигырьләр / З. Нури тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 54 б.
48 Баялинов К. Бәхет: Повесть һәм хикәяләр / Кыргызчадан Н. Гамбәров тәрҗ. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 116 б.
49 Айтматов Ч. Җәмилә: Повесть. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1962. – 88 б.; Айтматов Ч.. Повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. – 314 б.; Айтматов Ч. Повестьлар: Бәхил бул, Гөлсары! Анам кыры. Дөя күзе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 320 б.; Айтматов Ч. Бер көн – бер гомер. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 287 б.; Айтматов Ч. Сайланма әсәрләр: Роман, повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 574 б.
50 Солтанов О. Йолдызлы төннәр: Шигырьләр / Төз. Л. Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 95 б.
51 Сарманбетов А. Изге үр: Хикәяләр / Төз. Л. Шәех. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. – 207 б.
52 Госманов М. Олы мәхәббәт, якты моң җырчысы // Казан утлары. – 1978. – № 12. – Б. 94–95.
53 Госманов М. Бирелмичә калган сораулар // Казан утлары. – 2009. – № 5. – Б. 119.
54 Миннегулов Х.Ю. Чингиз Айтматов в татарском мире // Научный Татарстан. – 2019. – № 1. – С. 70–80.
55 Әскәров Т. Рухи байлыгыбыз арта // Социалистик Татарстан. – 1972. – 13 сент.
56 Айтматов Ч. Юлыбыз бер // Социалистик Татарстан. – 1972. – 13 сент.
57 Хикәя турында сөйләшү // Социалистик Татарстан. – 1972. – 16 сент.
58 Сыдыкбеков Т. Элемтәләр үссен! // Социалистик Татарстан. – 1972. – 10 сент.
59 Тукай Г. Тандамалуу ырлар жана поэмалар. – Кыргызмамбас, 1948. – 83 б.
60 Тукай Г. Тандалган чыгармалар / Котор.: К. Жунусов, У. Абдукаимов. – Кыргызмамбас, 1962. – 190 б.
61 Җунусов К. Тукай яши // Совет әдәбияты. – 1961. – № 4. – Б. 45.
62 Жыргалбеков Т. Габдулла Тукай // Ленин жолу. – 1962. – 28 апр.; Качегулова Д. Габдулла Тукай: Туулган күнүнө 100 жыл // Кыргызстан маданияты. – 1986. – 24 апр.; Көрүнүктүү татар жазуучусу // Ленин жолу. – 1966. – 26 апр.; Мурадымов Н. Ал элдин жүрөгүндө: Габдулла Тукайдын туулган күнүнө 90 жыл // Кыргызстан маданияты. – 1976. – 29 апр.; Тукай // Советтик Кыргызстан. – 1966. – 26 апр.
63 Абдылдабеков К. Произведения Мусы Джалиля в переводах киргизских поэтов // Муса Джалиль: материалы всесоюз. науч. конф., посвящ. 70-летию со дня рожд. поэта-героя / Отв. ред. Н. Юзеев. – Казань, 1978. – С. 92.

64 Жалил М. Тандалма чыгармалар. – Фрунзе: Кыргызстан мамлекеттик басмасы, 1957. – 231 б.

65 Жалил М. Менин ырларым. Өспүрүмдөр үчүн / Татар. котор. Т. Байзаков. – Фрунзе: Кыргыз Мамлекеттик Оку-Педагогика Басмасы, 1962. – 160 б.

66 Жалил М. Моабит дептери: Ырлар. – Фрунзе, 1979. – 64 б.

67 Жигитов С. Учкул канатынан айрылган поэзия // Ала-Тоо. – 1958. – № 5. – Б. 146–154.

68 Абдылдабеков К. Произведения Мусы Джалиля в переводах киргизских поэтов // Муса Джалиль: материалы всесоюз. науч. конф., посвящ. 70-летию со дня рожд. поэта-героя / Отв. ред. Н. Юзеев. – Казань, 1978. – С. 92.

69 Насыйбуллин М. Тыгыз элемтәләр // Социалистик Татарстан. – 1987. – 16 авг.

70 Шаех Л. Балбан бала = Амбал малай / Кыргызчага которгна А. Сарманбетов. – Бишкек: Рекламир, 2016. – 32 б.

71 Кара жорго, Акбозат: Котормолор / Котор. А. Сарманбетов. – Бишкек: Турар, 2020. – 184 б.

72 Кыргызстан мәдәнияте көннәре // Мәдәни җомга. – 2017. – 30 июнь.

73 Нигъмәтуллина З. Кыргыз илендә – татар рәссамы // Мәдәни җомга. – 2021. – 30 июль.

74 Шунда ук.